**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**

**Мәлбагыш авыл җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

Мәлбагыш авылы № 55 28 июнь 2017 ел

«Азнакай муниципаль районы җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләр (вәкаләтләр өлеше) тапшыру турында» 2015 елның 01июнендәге 134 номерлы Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Советының карарына үзгәреш кертү хакында

"Террорчылыкка каршы тору турында" Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына террорчылыкка каршы тору һәм җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча өстәмә чаралар билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында" 2016 елның 6 июлендәге 374-ФЗ номерлы Федераль законнарны үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Азнакай шәһәр прокуратурасының 2017 елның 10 февралендәге 02-03-01/173-15-2017 номерлы тәкъдимен карап,

Мәлбагыш авыл җирлеге Советы карар итте:

1. «Азнакай муниципаль районы җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләр (вәкаләтләр өлеше) тапшыру турында» 2015 елның 01июнендәге 134 номерлы Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Советының карарына үзгәреш кертергә, 1 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп:

"- террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалауда, шулай ук җирлек чикләрендә террорчылыкны һәм (яисә) экстремизм нәтиҗәләрен минимальләштерүдә һәм (яисә) юкка чыгаруда катнашу (әлеге мәсьәләне муниципаль район территориясендә тулаем алганда җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итү вәкаләтләреннән тыш), шул исәптән:

террорчылыкны профилактикалау, шулай ук аның чагылышларын минимальләштерү һәм (яисә) юкка чыгару өлкәсендә муниципаль программалар эшләү һәм гамәлгә ашыру;

җирлектә террорчылыкның асылын һәм аның иҗтимагый куркынычын аңлату буенча мәгълүмати-пропаганда чараларын оештыру һәм үткәрү, шулай ук

гражданнарда террорчылык идеологиясен кабул итмәү юлларын булдыру, шул исәптән мәгълүмати материаллар, матбугат продукциясе тарату, аңлату эшләре һәм башка чаралар үткәрү юлы белән;

терроpчылыкны профилактикалау, шулай ук федераль башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан оештырыла торган аның чагылышларын минимальләштерү һәм (яисә) бетерү чараларында катнашу;

муниципаль милектәге яисә җирле үзидарә органнары карамагындагы объектларның террорчылыктан сакланышына карата таләпләрне үтәүне тәэмин итү;».

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Мәлбагыш авыл җирлеге башкарма комитетына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты белән җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турындагы килешүгә өстәмә килешү төзергә.

3. Әлеге карарны Мәлбагыш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча: http://aznakayevo. tatarstan.ru урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны икътисад һәм финанс мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис И.Ә.Әхтәмова